**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023елның 21 ноябре 3672 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 7 сентябрендәге 64-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, территорияне тотрыклы үстерүне, инженерлык, транспорт, социаль һәм торак инфраструктурасын үстерүне тәэмин итү максатларында, КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 7 сентябрендәге 64-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты материалларының түбәндәге составын билгеләргә:

1) территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;

2) җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;

3) җирлек составына керүче торак пунктларның чикләре картасы;

4) җирлекнең функциональ зоналары картасы;

5) күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең үзгәрүче урыны график тасвирламасы, әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге булырга тиешле җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре турында белешмәләр;

6) Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын нигезләү материаллары.

3. Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләү 100% күләмендә инвестор хисабына башкарылачак, башкарылган эшләр өчен түләү аларны үтәү факты буенча башкарылачак дип билгеләргә.

4. Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләренең түбәндәге этапларын билгеләргә:

| Этап номеры | Эш этабы исеме |
|---|---|
| 1 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә контракт төзү |
| 2 | Проектны әзерләү |
| 3 | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында үзгәрешләр кертү проектын килештерү |
| 4 | Генераль планга үзгәрешләр кертү проектын раслау өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрү |

5. Генераль планны әзерләү эшләрен оештыруны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

6. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**